**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 166**
**27.05.2015 ел**

Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Кешеләр күпләп җыела торган объектларны категорияләүне үткәрү максатында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны һәм полиция тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны (территорияләрне) терроризмнан саклауга карата таләпләрне һәм шундый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынчсызлык паспортлары формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 санлы карары, шәһәр Уставының 35 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) төзергә.

2. Расларга:

1) комиссия турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе Н.Г. Мәһдиевка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2015 елның 27 маендагы
М 166 нчы карарына
1 нче кушымта

# Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезнамә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия), кешеләр күпләп җыела торган урыннарда терроризм актлары кылуның һәм аларның мөмкин булган тискәре нәтиҗәләренең потенциаль куркынычы дәрәҗәсен исәпкә алып, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата дифференцияләнгән таләпләр билгеләү өчен кешеләр күпләп җыела торган урыннарны категорияләүне үткәрүне оештыру максатында төзелгән даими эш итүче координация органы булып тора.

2. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерүне һәм категорияләүне үткәрергә;

2) кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү актлары төзергә;

3) кешеләр күпләп җыела торган урынның куркынычсызлык паспортын төзергә һәм аны актуальләштерүне үткәрергә;

4) кешеләр күпләп җыела торган урыннарны терроризмнан саклауны тәэмин итү буенча чараларны билгеләргә;

5) кешеләр күпләп җыела торган урыннарны терроризмнан саклауга карата таләпләрнең үтәлешен план буенча һәм планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырыга.

3. Комиссия составы Яр Чаллы шәһәре Хакиме карары белән раслана.

## 2 бүлек. Комиссиянең эш тәртибе

4. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

5. Комиссия белән комиссия рәисе җитәкчелек итә.

Комиссия рәисе булмаган вакытта, рәис вәкаләтләтләрен комиссия рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

6. Комиссия рәисе:

1) комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, көн тәртибен, комиссия утырышларында мәсьәләләрне карау срокларын һәм тәртибен билгели;

2) комиссия утырышларын үткәрүгә инициатива күрсәтә;

3) комиссия утырышларын алып бара;

4) кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү актларын һәм комиссия вәкаләтләрен үтәүгә кагылышлы башка документларны имзалый.

7. Комиссия составына түбәндәгеләр кертелә:

1) кешеләр күпләп җыела торган урынның хуҗасы яки кешеләр күпләп җыела торган урынны законда каралган башка нигездә файдаланучы зат;

2) территориаль куркынычсызлык органы вәкилләре;

3) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органы вәкилләре;

4) Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының территориаль органы вәкилләре.

8. Кирәк булганда комиссия эшенә кешеләр күпләп җыела торган урын чикләрендә яисә аңа якын урнашкан объектларның хуҗалары җәлеп ителә.

9. Комиссиянең эш нәтиҗәләре кешеләр күпләп җыела торган урынны тикшерү һәм категорияләү акты белән рәсмиләштерелә, ул 5 нөсхәдә төзелә, комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм кешеләр күпләп җыела торган урынның куркынычсызлык паспортының аерылгысыз өлеше булып тора.

10. Кешеләр күпләп җыела торган һәр урынга тикшерү һәм категорияләү үткәрелгәннән соң, комиссия тарафыннан 5 нөсхәдә кешеләр күпләп җыела торган урынның уркынычсызлык паспорты төзелә, ул территориаль куркынычсызлык органы, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының территориаль органнары җитәкчеләре белән килешенә һәм Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан раслана.

Муниципаль берәмлек<br>
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2015 елның 27 маендагы
М 166 нчы карарына
2 нче кушымта

Кешеләр күпләп җыела торган урынны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Абдуллин Ринат Әзһәр улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 2. | Гыймадиев Румил Миргазиян улы | комиссия рәисе урынбасары, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| | комиссия әгъзалары: | |
| 3. | Викентьев Игорь Иванович | ТР буенча РФ Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге хезмәте башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| 4. | Ибраһимов Айдар Барый улы | Башкарма комитет халык иминлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 5. | Мингалиев Рәүф Минрәхим улы | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| 6. | Мясников Евгений Геннадьевич | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе оператив бүлегенең өлкән инспекторы (килешенү буенча) |
| 7. | Тарабукин Алексей Сергеевич | коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча шәһәр Хакиме ярдәмчесе (килешенү буенча) |
| 8. | Репина Людмила Леонидовна | ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| 9. | Фатыйхов Ирек Габделхәй улы | Яр Чаллы шәһәре буенча ТР ГТХМ идарәсе башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| 10. | Фирстова Марина Рәшид кызы | Яр Чаллы шәһәре буенча ТР ГТХМ идарәсе белгече (килешенү буенча) |
| 11. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгының беренче урынбасары. |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева